ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«16» март 2020 ел № 40-р

2020 елның 01 апреленнән 2020 елның 31 маена кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык үткәрү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитар-экологик икеайлык үткәрү турында» 2020 елныц 24 февралендәге 388-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән:

1. Расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен чистарту, төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча санитар-экологик икеайлыкны оештыру һәм үткәрү буенча оператив штаб составын (1 нче кушымта);

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен чистарту, төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елныц 31 маена кадәрге чорда санитар-экологик икеайлык чаралары планын (2нче кушымта).

3. Әгерҗе муниципаль районының оешма, предприятие, учреждение җитәкчеләренә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, Әгерҗе шәһәре һәм Әгерҗе муниципаль районы халкына беркетелгән территорияләрдә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре торак пунктлары территорияләрен чистарту, төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча санитар-экологик икеайлык чаралары планын үтәргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 31 маена кадәрге чорда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен чистарту, төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча санитар-экологик икеайлык оештырырга һәм үткәрергә, Әгерҗе муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләрен төзекләндерү буенча муниципаль Кагыйдәләрнең, калдыклар белән эш итүнең муниципаль Кагыйдәләрнең үтәлешен тикшереп

торуны көчәйтү өлешендә эшне активлаштырырга, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм әйбер базарларын, халык күпләп ял итә торган урыннарны санитар чистарту буенча чаралар үткәрергә, санитар-экологик икеайлыкның оператив штабына атна саен (һәр җомгада) башкарылган эшләр турында мәгълүмат бирергә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МУП «Төзелеш идарәсе»нә каты көнкүреш калдыклары полигонын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм аның янәшәсендәге урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрергә.

6. Санитар-экологик икеайлыкны оештыру һәм үткәрү буенча оператив штабка буйсынуындагы территорияләрдә «Татарстан Республикасының Экологик картасы» геомәгълүмат системасы ярдәмендә рөхсәтсез калдыклар ташлау урыннарын бетерү мониторингы үткәрергә (http://ecokarta.tatar.ru).

7. «Агрызские вести» («Әгерҗе хәбәрләре») район газетасы мөхәрриренә шәһәр һәм авыл җирлекләре территориясендә санитар-экологик хәлне саклау, территорияләрне санитар-экологик чистартуда катнашуны тәэмин итү турында халык арасында аңлату эшләре алып барырга тәкъдим итәргә.

8. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына икеайлык үткәрү буенча эшләрнең барышы турында белешмәләр тапшырырга.

9. Әлеге күрсәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://agryz.tatarstan.ru.

10. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
16 март 2020ел, № 40-р
күрсәтмәсенә 1нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен чистарту, төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча санитар-экологик икеайлыкны оештыру һәм үткәрү буенча оператив штаб составы**

| № | ФИО | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Шәмсетдинов И.И. | Оператив штаб рәисе,<br>Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары |
| *Комиссия әгъзалары:* | | |
| 2. | Рәхмәтулин А.М. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча) |
| 3. | Хаҗиева Л.Р. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы |
| 4. | Шәрипова Л.Р. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| 5. | Закиров Р.Р. | Тирсә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча) |
| 6. | Лазарев А.Н. | Красный Бор авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча |
| 7 | Гисматуллина Р.Т. | Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Алабуга районы һәм Әгерҗе шәһәре территориаль бүлеге башлыгы (килештерү буенча) |
| 8. | Ниязов Р.Э. | Административ комиссиянең баш белгече (җаваплы секретаре) |
| 9. | Хисматов Р.Ф.. | “Әгерҗе район дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДУ башлыгы (килештерү буенча) |
| 10. | Шәйдуллин А.Р. | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Әгерҗе муниципаль районы буенча МЧС Баш идарәсе башлыгы (килештерү буенча) |

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
16 март 2020ел, № 40-р
күрсәтмәсенә 2нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен чистарту, төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 31 маена кадәрге чорда санитар-экологик икеайлык чаралары планы**

| № | Чаралар | Үткәрү сроклары | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Предприятиеләр, оешмалар һәм ведомстволар көче белән җыештырылырга тиешле шәһәр территорияләре исемлеген билгеләү һәм беркетү. | 31.03.2020 | "Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килештерү буенча) |
| 2. | Халык тарафыннан шикаятьләрне төшереп калдыру максатыннан, гражданнарның милек хокукында булган йортларда, бакчачылык ширкәтләрен һәм гараж кооперативларын да кертеп, төзелеш районнарында каты көнкүреш калдыкларыннан планлы-даими чистартуның сыйфатын арттыру. | Апрель | Әгерҗе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары (килештерү буенча);<br>"Хәлим" КФК (килештерү буенча);<br>“Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе" МУП |
| 3. | Оешма-предприятиеләрдән, шәхси эшмәкәрләрдән көнкүреш калдыкларын чыгаруга шартнамәләр төзүнең вакытында тутырылуын тикшерү һәм анализ үткәрү. | Апрель | “Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе" МУП |
| 4. | Канализациясез йортлардагы чүп-чар җыю урыннарын, бәдрәфләрне вакытында чүп-чардан арындыру. | Апрель-май | Төзелеш оешмалары, учреждениеләре, предприятиеләр (килештерү буенча) |
| 5. | Торак пунктларның, сулыкларның, чишмәләрнең территорияләрен чистарту, коймаларны төзекләндерү буенча максатчан өмәләр оештыру. | Апрель-май | "Әгерҗе муниципаль районы" төзелеш идарәсе " МУП<br>Әгерҗе муниципаль районы оешмалары, учреждениеләре, предприятиеләре (килештерү буенча);<br>"СМП-184" ИК (килештерү буенча);<br>Авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | (килештерү буенча);<br>"Әгерҗе шәһәре" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килештерү буенча) |
| 6. | Шәһәр һәм КФЙ буенча агач һәм куаклар утыртуны, чәчәк түтәлләрен урнаштыруны һәм газоннарны, йорт яны территорияләрен төзекләндерүне оештыру | Атнага 1 тапкыр | “Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе" МУП,<br>ИК "СМП-184" (килештерү буенча);<br>авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре (килештерү буенча);<br>ТСЖ, ТҖҮ (килештерү буенча) |
| 7. | Сәүдә нокталары, җәмәгать туклануы объектлары һәм базарларда тирә-юнь территорияләрендә санитар законнарның үтәлешен тикшерү | Даими | Роспотребнадзорның ТР буенча территориаль идарәсенең Алабуга районы һәм Әгерҗе шәһәре территориаль бүлеге (килештерү буенча) |
| 8. | Каты һәм сыек көнкүреш калдыкларын зарарсызландыруны махсус билгеләнгән участокларда яки зарарсызландыру һәм эшкәртү буенча махсус корылмаларда башкару | Даими “Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе" МУП | Оешмалар, учреждениеләр, предприятиеләр, шәхси эшмәкәрләр, шәхси затлар (килештерү буенча) |
| 9. | Мәйданнарда, урамнарда, базарларда, шәһәр транспорты тукталышларында һәм башка җанлы урыннарда чүплекләрне тикшерү | 2020 ел дәвамында “Әгерҗе муниципаль районының төзелеш идарәсе" МУП | Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар |
| 10 | Терлекчелек фермалары һәм башка җитештерү объектлары территорияләрен санитар чистарту | даими | Авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре (килештерү буенча);<br>авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре (килештерү буенча);<br>гаилә фермалары җитәкчеләре, фермер хуҗалыклары (килештерү буенча) |